

Викторина

# “ӨЗЕЛГӘН ҖЫР ЭЗЕННӘН”


# 1нче сорау:

- “...Әкияттәге серле йомгак булып,
- Җырым сүтелеп калды юлымда,
- Сез табарсыз килеп шушы эздән

Мине шушы йөрәк җырымнан”, - дип язган шагыйрь.

Муса Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнүчеләрдән кемнәрне беләсез?

# Җавап:



Рафаэль Мостафин

# 2нче сорау:

“...Аның өчен күргән авырлыклар,

Читенлекләр бер дә сизелми.

Кырык чирне алып үз өстемә,

Аны саклап калыр идем мин...”.

Бу юллар кемгә багышланган?





# Җавап:

Бу юллар “Ул үскәндә” дигән кызы Чулпанга багышланган шигырьдән.







# Энче сорау:

Шагыйрьнең тормыш иптәше турында нәрсәләр беләсез?



# Җавап:

Әминә Котдус кызы Җәлилова



# 4нче сорау:

Татарстан Республикасында Муса Җәлил исеме белән бәйле нинди урыннарны беләсез?

Иске Кулаткы бистәсендә андый урыннар бармы?

# Җавап:




Минзәлә шәһәрендәге музей, Чаллыдагы проспект, Казанда Муса Җәлил урамы, опера һәм балет театры, һәйкәл, музее.





Иске Кулаткы бистәсендә №1 урта мәктәптә Муса Җәлил музее һәм аның исемендә урам бар.



# 5нче сорау:

Ни өчен Казандагы опера һәм балет театры Муса Җәлил исемен йөртә?



# Җавап:

Театрның чишмә башында Муса Җәлил торган. Опера сәнгатен салуга күп көч куя.1938 -1941 елларда опера һәм балет театрында әдәбият – репертуар бүлеге җитәкчесе булып эшли. “Илдар”, “Алтынчәч”, “Балыкчы кыз” либреттоларының авторы да Муса Җәлил.

# 6нчы сорау:

Шагыйрьнең биографиясендә 1956, 1957 еллар нәрсә белән истәлекле?






# Җавап:

1956 елда Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1957 елда “Моабит дәфтәрләре шигырьләр циклы өчен Ленин премиясе белән бүләкләнә.

# 7 -8 нче сорау:

Казанда ничәнче елда Муса Җәлилгә һәйкәл куелган?

Аның авторы кем?



# Җавап:

Казанда 1966 елда М. Җәлилгә һәйкәл куелган. Авторы В.Е. Цигаль.



Һәйкәлгә өстәмә барельеф кайчан эшләнгән?



1994 елда. Җәлилчеләр үлеменә 50 ел тулган көнне.



# 10нчы сорау:

Шагыйрь белән бергә тоткынлыкта фашистлар тагын кемнәрне җәзалыйлар?



# Җавап :

Гайнан Курмаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов,Әхәт Әтнашев, Сәлим Бохараев.

- **Җәлилчеләр исемлеге**
- Исеме.Үлем датасы.Үлем сәгате.Туган ягы.
- Гайнан Кормаш1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 06 минутАктүбә, Казакъстан
- Фоат Сәйфелмөлеков1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 09 минутТашкент, Үзбәкстан
- Абдулла Алиш1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 12 минутКөек, Татарстан
- Фоат Булатов1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 15 минутМәләвез, Башкортстан
- Муса Җәлил1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 18 минутМостафа, Ырымбур өлкәсе

- Гариф Шабаев1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 21 минутИске Турай, Башкортстан
- Әхмәт Симаев1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 24 минутУсть-Рахмановка, Пенза өлкәсе
- Абдулла Баттал1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 27 минутЗур Тигәнәле, Татарстан
- Зиннәт Хәсәнов1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 30 минутИске Кәшер, Татарстан
- Әхәт Атнашев1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 33 минутПетропавловск, Казакъстан
- Сәлим Бохаров1944 нче ел, 25 нче август12 сәгать 36 минутМиякә, Башкортстан

# 11нче сорау:

Шагыйрьнең “Моабит дәфтәрләре” безнең илгә кайчан килеп җитә? Ул дәфтәрләрне саклап калып, безнең илгә кайтарып бирүчеләрне беләсезме?



# Җавап :

1946, 1947 елларда. Габбас Шәрипов, Нигъмәт Терегулов, Андре Тиммерманс.



Андре Тиммерманс, Әминә ханым һәм Чулпан

# 13нче сорау:

Ни өчен 1953 елның 25 апреле М. Җәлилнең икенче туган көне булып санала?

# Җавап :

Бу көнне “Литературная газета” да “Моабит дәфтәре”ннән шигырьләре басылып чыга.

# 14нче сорау:

М. Җәлил сүзләренә язган кайсы композиторларны беләсез?

# Җавап:

Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин.





# 15нче сорау:

М Җәлил нинди уен коралында уйный белгән?



# Җавап:

Мандолинада.






# 16нчы сорау:

Язучының балалар өчен язылган шигырьләрнең исемнәрен әйтегез.

“Кызыл ромашка”, “Карак песи”,”Кыңгырау”, “Күке”, “Сәгать”, “Парашютсыз курчак” һ.б.









# 17нче сорау:

М.Җәлилгә багышланган “Хәкем алдыннан” картинасының авторы кем?



# Җавап :

1954 елда Харис Якупов җәмәгатьчелекне үзенең «Хөкем алдыннан» дигән атаклы картинасы белән таң калдыра. Картинада фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән каһарман шагыйрь Муса Җәлил сурәтләнә.

# 18нче сорау:

М. Җәлил исемен йөрткән планета кайчан һәм кем тарафыннан ачылган?



Җавап:
3092 нче әлеге кече планета “Җәлил” астероиды. Кырымдагы астрофизик обсерваториясендә астроном Т. Смирнов тарафыннан 1972 елда ачыла.



